МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.02.2019 г. Казань № под-303/19

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 25.07.2014 ел, 4231/14 номерлы боерыгы белән расланган Квалификация категориясен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын төзү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 02.11.2010 ел, 880 номерлы карары нигезендә б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Квалификация категориясен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Административ регламентын раслау турында» (22.06.2016 ел, ПУ-1244/16 номерлы боерыгы белән кертелгән

үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - Регламент) 25.07.2014 ел, 4231/14 номерлы боерыгы белән расланган Квалификация категориясен билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен аттестацияләү өчен дәүләт хезмәте күрсәтү буенча Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1 нче бүлектә:

1.3 пунктының 1.3.1 пунктчасындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Министрлыкның эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбе көннәреннән кала, дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга көнне - 9.00 дән 16.45 кә кадәр, төшке аш 13.00 дән 13.45 кә кадәр. Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00 дән 18.00 гә кадәр, җомга көнне - 9.00 дән 16.45 кә кадәр, төшке аш 13.00 дән 13.45 кә кадәр.»;

1.3 пунктының 1.3.4 пунктчасындагы алтынчы абзацын «мәгълүмат» сүзе алдыннан «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә» сүзләре белән тулыландырырга;

1.3 пунктының 1.3.5 пунктчасын «Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә» сүзләре белән тулыландырырга;

1.5 пунктының тугызынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күп функцияле үзәгенең читтән тоташулы эш урыны - Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә булдырылган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күп функцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы)»;

2 нче бүлектә:

2.13 пунктының «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлектәге абзац белән тулыландырырга:

«Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә килгән сорату ял көненнән (бәйрәмнән) соң килә торган эш көнендә теркәлә»;

5 нче бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Министрлыкның, шулай ук аның вазифаи затлары һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр Министрлыкның, шулай ук Министрлыкның вазифаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр Министрлыкка шикаять белдерергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән

карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

5.2. Мөрәҗәгать итүче шикаять белән, шул исәптән түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтүне теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәтен күрсәтү срокларын бозу;

3) мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яисә мәгълүматларны сорату яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) әгәр баш тарту өчен нигезләү федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Министрлыкның, аның вазифаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда ялгыш җибәрелгән төгәлсезлекләр һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрне башкару өчен билгеләнгән срокны бозуы;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар тапшыру срогын яки тәртибен бозу;

9) әгәр туктатып торуны нигезләү федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында каралмаган булса, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору;

10) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 маддәсендәге 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен яисә дәүләт хезмәтен күрсәткән вакытта булмаган һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән кирәкле документларны яисә мәгълүматны беренче тапкыр кабул итүдән баш тарткан очракта таләп итү.

5.3. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Министрлыкның, Министрлыкның вазифаи затының, Министрлыкның дүләт хезмәткәренең, министрның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта, "Интернет" челтәреннән файдаланып күпфункцияле үзәк, Министрлыкның рәсми сайты (http://mon.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru/) аша җибәрелә ала, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин..

5.4. Шикаять үз эченә түбәндәгеләрне алырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять белдерелә торган Министрлык, Министрлыкның вазифаи заты яисә дәүләт граждан хезмәткәре исеме;

2) мөрәҗәгать итүче - физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләре яисә мөрәҗәгать итүче - юридик затның урнашкан урын турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номер(лар)ы һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле электрон почта адресы (булган очракта) һәм почта адресы;

3) Министрлыкның, аның вазифаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең дәгъвалана торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) Министрлыкның, аның вазифаи затының яисә дәүләт граждан хезмәткәренең карары һәм эше (гамәл кылмавы) белән мөрәҗәгать итүче килешмәгән дәлилләр. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.5. Гариза тапшыручы шикаятьне нигезләү һәм карау өчен кирәкле мәгълүматны һәм документларны алырга хокуклы

5.6. Шикаятьне карау вакыты - теркәлгән көннән алып 15 эш көне эчендә. Министрлык, Министрлыкның вазифаи заты мөрәҗәгать итүчедән документлар кабул итүдән баш тарткан очракта яисә төгәлсезлекләр һәм хаталарны төзәткәндә яисә мондый төзәтмәләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять бирелгән очракта - теркәлгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Шикаятьне карау нәтиҗәләренә нигезләнеп түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, әүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда киткән төгәлсезлекләрне һәм хаталарны төзәтү, түләтү Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган акчаларны мөрәҗәгать итүчегә кире кайтару рәвешендә канәгатьләндерелә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән, карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язма рәвештә һәм, мөрәҗәгать итүченең теләге буенча электрон рәвештә, шикаятьне карау нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

Шикаятьне канәгатьләндерергә тиешле дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта Министрлык тарафыннан башкарыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, ачыкланган хокук бозуларны дәүләт хезмәте күрсәткәндә кичекмәстән бетерү максатларында, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында мөрәҗәгать итүчегә алга таба башкарырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат хәбәр ителә.

Шикаятьне канәгатьләндерелми дип таныган очракта, мөрәҗәгать итүчегә кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.8. Шикаятьне карап тикшерү барышында яисә нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яисә җинаятьләр составы билгеләре ачыкланган

очракта, шикаятьләрне карау вәкаләтләренә ия вазифаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.. » ^ Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Квалификация категориясе билгеләү
максатларында, Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
Татарстан Республикасында белем бирү
эшчәнлеген гамәлгә ашыручы
оешмаларның педагогик хезмәткәрләрен
аттестацияләү өчен дәүләт хезмәте
күрсәтү буенча административ
регламентына
2 нче кушымта

КВАЛИФИКАЦИЯ КАТЕГОРИЯСЕН БИЛГЕЛӘҮ МАКСАТЛАРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЧӘНЛЕГЕН ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ ОЕШМАЛАРНЫҢ ПЕДАГОГИК ХЕЗМӘТКӘРЛӘРЕН АТТЕСТАЦИЯЛӘҮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮГӘ ҖАВАПЛЫ ОРГАННАРНЫҢ ҺӘМ ВАЗИФАИ ЗАТЛАРНЫҢ РЕКВИЗИТЛАРЫ

| Вазифа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр Борханов Рафис Тимерхан улы | Т/ф. 292-92-12, 294-95-90 факс 2924480 | mon@tatar.ru http://www.mon.tatar.ru |
| Кадрлар сәясәте бүлеге мөдире Әмирова Лилия Сәлимҗан кызы | Тел. 294-95-31 Факс 294-95-31 | Liliya.Amirova@tatar.ru |
| Кадрлар сәясәте бүлегенең әйдәп баручы консультанты Шәяхмәтова Гөлзада Мөдәрис кызы | Тел. 294-95-33, факс: 294-95-33 | Gulzada.Shayahmetova@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты
Югары, урта, һөнәри белем бирү һәм фән бүлеге

| Вазифа | Телефон | Адрес |
|---|---|---|
| Бүлек мөдире Выборнов Андрей Андреевич | 264-77-20 | 420060, Казань шәһәре, Ирек мәйданы, 1 нче йорт |
| Мөдир урынбасары Низамова Ләйсән Гаптелхан кызы | 264-76-84 | |

2. Кадрлар сәясәте бүлеге мөдиренә (Л.С. Әмирова) боерыкка кул куелган көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә аны дәүләт теркәвенә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министрның беренче урынбасары И.Г. Хәдиуллинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министр
урынбасары - министр Р.Т. Борһанов